КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 31 октябрь г.Казань № 945

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасының Алексеевск һәм Чистай муниципаль районнары территориясендә «Татарстан Республикасында «Татарстан Республикасында «Шәле (М-7) – Баулы (М-5)». 1 нче этап – 0+00 км – 43+216 км» түләүле автомобиль юлы составында «Алексеевск – Әлмәт» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын булдыру максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 декабрь, б-2668 нче; 2023 ел, 8 декабрь, б-2800 нче боерыклары, 2022 елның 11 гыйнварындагы КС-17/98 номерлы концессия килешүе нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Автострада» акционерлык җәмгыятенең Татарстан Республикасы Алексеевск һәм Чистай муниципаль районнары территориясендә «Татарстан Республикасында «Татарстан Республикасында «Шәле (М-7) – Баулы (М-5)». 1 нче этап – 0+00 км – 43+216 км» түләүле автомобиль юлы составында «Алексеевск – Әлмәт» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын булдыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Мөслим авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, А.Н.Чернышев (алга таба – алына торган җир кишәрлеге милекчесе) милкендә булган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясендәге 127 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге) 16:42:100501:305 кадастр номеры белән алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районындагы Мөслим авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеге милекчесенә, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, «Автострада» акционерлык җәмгыятенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлеге милекчесе тарафыннан имза куелган килешү законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

3. «Автострада» акционерлык җәмгыятенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләү күләмен билгеләүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләүне.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                   А.В.Песошин